**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КОНОВАЛОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**423719,Республика Татарстан Мензелинский район, с. Коноваловка, ул. Центральная, 5**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОНОВАЛОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423719, Татарстан Республикасы, Минзәлә районы, Коноваловка авылы, Центральная урамы,5**

телефон: (85555) 2-34-47. E-mail Kval.Mnz@tatar.ru
ОКПО 92640440 ОГРН 1061682001700 ИНН/КПП 1628006461/162801001

Минзәлә муниципаль районының
Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от « 27 » март 2020 ел. №1

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Коноваловка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында”гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Коноваловка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Билалова С.А..

ТР Минзәлә муниципаль районы
Коноваловка авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27  март 2020 ел. N 1

ТР Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Минзәлә шәһәре территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:
- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары,
- 1 һәм 2 төркем инвалидлар;
- биш һәм аннан күбрәк балалы күпбалалы әниләр.

Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:
а) авыру;
б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнең мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ________________ Минзәлә муниципаль районы Коноваловка авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________________________

Адресы: ______________________________________________________

______________________________________________________ нигезендә

Сезгә _____________ срокка кадәр _________________________ чараларны гамәлгә

__________________________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада ________________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча:___________________

Түләү алучы банкның БИК ____________________________________________
Сч. N ____________________________________________________________
Кабул итүче Сч. N _________________________________________________
КПП ______________________________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләнеше _________________________________________________
Җитәкче __________________ ___________________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N __________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында _______________________
__________________________________________________________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада _________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ____________________________________________
Адресы: ________________________________________________________
Алдым "___" ________________ 20___ ел. ________________________________________

________________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.